**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карары**

Татар Шуганы авылы №181 27 июль 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 12 октябреннэн 52 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (07.10.2013 №69, 17.03.2014 №93, 15.08.2014 №111, 25.08.2017 №62, 28.01.2019 №125 нче номерлы карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 12 октябреннэн 52 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (07.10.2013 №69, 17.03.2014 №93, 15.08.2014 №111, 25.08.2017 №62, 28.01.2019 №125 нче номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.11.13 пунктта:
а) «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;
б) «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.2. 2.11.16 пунктта «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.18 пункт белән тулыландырырга:
«2.11.18. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.З.Мияссәрова